ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2019 г. Заинск №648

**“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2016 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында”**

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2019 елның 02 ноябрендәге 1008 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 1864 номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 151 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күрсәтелгән карар белән расланган Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

а) V бүлекнең 2 пунктының сигезенче абзацында «300» санын «550» санына алмаштырырга;

б) VI бүлекнең 15 пунктында, 15.11 пунктындагы бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Зәй муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең V бүлегенең 12 пунктында, 12.11 пунктындагы бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Зәй муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең VI бүлегенең 8 пунктында, 8.11 пунктындагы бишенче һәм җиденче абзацларында «һәм төп вазыйфа» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Л.Р. Печина
3-27-42